| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 май № 298

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы-ның дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче һәм 2016 ел, 27 апрель, 252 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 32 нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «32 | 2016 – 2020 елларга Татарстан Рес- | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ми- | Перспективалы конкурентлык сәләтенә ия продукция җитештерү өчен модерни- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | публикасы сәнәгатенең эшкәртүче тармакларын үстерү | сәүдә министрлыгы | нистрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, республика предприятиеләре, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирә торган мәгариф оешмалары (килешү буенча) | зацияләү һәм яңадан техник коралландыру проектларын тормышка ашыруны стимуллаштыру; сәнәгатьнең эшкәртүче тармакларындагы республика предприятиеләренең Россия һәм чит ил эре компанияләре белән кооперациясен үстерү; инновацион технологияләр эшләү һәм кертүгә, Татарстан Республикасы предприятиеләренең интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен саклауга булышлык күрсәтү; сәнәгатьнең эшкәртүче тармакларындагы предприятиеләрдә җитештерү һәм хезмәт җитештерүчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча корпоратив программаларны тормышка ашыруга, «сакчыл җитештерү» принципларын кертүгә булышлык күрсәтү; конкурентлыкка сәләтле производстволар төзү һәм үстерү проектларын фәнни һәм кадрлар белән тәэмин итүне оештыру нәтиҗәлелеген күтәрү; югары өстәмә кыйммәте булган продукция экспортын арттыру». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков